«Согласовано»
Заместитель директора по ВР
МБОУ «Малоцильнинская сош
имени Арсланова З.М. »
_________ / Э.А.Низамова
«28» августа 2025 г.

«Утверждаю»
Директор
МБОУ «Малоцильнинская сош
имени Арсланова З.М.»
_________ Г.К.Миначева
Приказ № 151
от «18» августа 2025 г.

# Рабочая программа

**школьного кружка**

## *«Сәхнә теле"*

**5, 6 класс**

**МБОУ «Малоцильнинская сош имени Арсланова З.М.»**

**Дрожжановского муниципального района РТ**

**Руководитель: Залалдинова Гульназ Замиловна**

Рассмотрено на заседании
педагогического совета
протокол № 1
«29» августа 2025 г.

2025/ 2026 учебный год

**“Сәхнә теле” театр түгәрәге программасы.**

5, 6 нчы сыйныф өчен, атнага 2 сәгать ( 68с.)

Төзүче: Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы “Арсланов З.М.исемендәге гомуми белем бирү мәктәбе” Залалдинова Гөлназ Җәмил кызы .

**Түгәрәк җитәкчесе турында мәгълүматлар**

1. Ф.И.О. — Залалдинова Гөлназ Җәмил кызы
2. Вазифасы — Түгәрәк җитәкчесе
3. Белеме — Югары, КДПУ, 2000 ел, филфак
4. Стажы — 31 ел
5. Туган елы — 1974 ел
6. Яшәү урыны — Чүпрәле районы, Кече Чынлы авылы

**Түгәрәк әгъзалары исемлеге**

| № п/п | Фамилиясе, исеме, этисенең исеме | 5, 6 сыйныф |
|---|---|---|
| 1 | Басырова Зәлинә Альфик кызы | 5 |
| 2 | Гайнетдинов Рамазан Рафаэль улы | 5 |
| 3 | Салимзянова Сәмирә Тәлгать кыз | 5 |
| 4 | Сатдинова Илзидә Ильнур кызы | 5 |
| 5 | Акберов Ранил Рамиль улы | 5 |
| 6 | Ахметзянова Илүзә Фәрит кызы | 5 |
| 7 | Хисамутдинова Айгөл Минхарис кызы | 5 |
| 8 | Мөхтәрова Азалия Айрат кызы | 6 |
| 9 | Хайбуллова Айзилә Ильнур кызы | 6 |
| 10 | Замултдинова Ралинә Рамил кызы | 6 |

**Аңлатма язуы.**

Театр – сәнгатьнең бер төре. Ул үз эченә әдәбият, музыка, бию, сынлы сәнгатьне берләштерә. Сәнгатьле сөйләм формалаштырганда балага белем бирү шартлары гына түгел, ә аларны эшкәртергә һәм үзләренең карашын билгеләргә дә мөмкинлек бирә. Моның өчен иң әйбәт чара булып театральләштергән шөгыльләр тора. Театр иң демократик, яшь үзенчәлекләренә туры килерлек сәнгать төре. Ул педагогик һәм психологик актуаль проблемаларны хәл итәргә булыша. Алар әхлак тәрбиясе бирергә, коммуникатив шәхес формалаштырырга, күзаллау, фантазия, инициатива, фикер йөртүгә, туган телне яратырга ярдәм итә. Театр сәнгате аша балалар образлар, тавыш, буяу аркылы әйләнә-тирә белән танышалар, зәвык һәм әхлак тәрбиясе алалар. Тормышның көзгесе булган әлеге сәнгать укучыларны яңа хисләр, белемнәр, күнекмәләр белән баетырга, матур әдәбиятка кызыксыну уятырга, сүз байлыгы, сөйләм телен үстерергә ярдәм итә.

Бүгенге көндә үсеп килүче яшь буынны халкыбызның традицияләре үрнәгендә тәрбияләү- мөһим бурычларның берсе. Балага милли гореф-гадәтләр, милли традицияләр никадәр иртәрәк бирелсә, ул шәхес буларак шулкадәр көчле, телен, илен, милләтен сөя белүче булып үсәчәк.Үз телен, милләтен, мәдәниятен белеп, аңа хөрмәт белән карый белүче генә башка милләт вәкилләрен, аларның гореф-гадәтләрен ихтирам итә белә. Туган телне, милли мәдәниятне өйрәнеп һәм янәшә яшәүче башка халыкларның да теленә, мәдәниятенә, милли традицияләренә тирән ихтирам белән карый белүче балалар безнең мәгариф һәм милли мәдәниятне үстерүнең нигез ташын тәшкил итәргә тиеш.

“Сәхнә теле” түгәрәге укучыларның сәләтләрен ачарга, уй- хыялларын үстерергә мөмкинлек бирә, матурлыкны күрә белергә өйрәтә, иҗади эшчәнлекне баета.Адәм баласы, укучылар хисләр дәрьясында яши, әйләнә-тирәдә булган вакыйгаларны йөрәге аша үткәрә. Бүгенге укучыларның күңел түрләренә үтеп кереп, аны уйланырга, нәтиҗә чыгарырга, сабак алырга ярдәм итүче иң кулай ысулларның берсе театр сәнгате дип уйлыйм. Җәмгыятьтә үз урыннарын табу, тормышның тайгак юлларында абынмау, үз кыйблаларын саклап калу, иң мөһиме камил шәхес тәрбияләү бурычы өстендә эшләү күз алдында тотыла.

**Театр түгәрәгенең максаты һәм бурычлары**

Укучыларны татар театр сәнгатен аңларга өйрәтү.
Татар театры тарихы, анынберенчекарлыгачлары, беренчеладымнарыбеләнкызыксынухисләреуяту.
Татар театры сәнгатенә мәхәббәттәрбияләү, әхлаксыйфатлары формалаштыру, киләчәктормышка әзерләү.
Сәнгатьлеукуһәмсөйләмкүнекмәләренүстерү.
Иҗадисәләтләрен үстерү һәмтирәнәйтү.
Театр сәнгатенең мәгънәсен аңлауларына ирешү.
Образларны тормышчан иҗат итү серләренә төшендерү.
Төрле бәйге-ярышларда, ата-аналар алдында чыгышлар ясау.
Сүз сәнгатеннән алган белемнәрен тагы да тирәнәйтү, гомумиләштерү.

**Түгәрәк эше буенча көтелгән нәтиҗәләр :**

-укучы үзен иркен тотарга өйрәнә, психологик яктан ачыла;
-үзенең мавыгуына туры килгән эш белән шөгыльләнә;
-түгәрәктәге укучылар, укытучы белән аралашу вакытында, эчке дөньясында ачыла, аралашу әдәбенә өйрәнә;
-укучы фикерләргә, үз фикерен дәлилләргә өйрәнә;
-сөйләм телен камилләштерә ;
-әхлак һәм зәвык тәрбиясе ала;
-шәхес булып тәрбияләнә, үз урынын таба;
-татар теле һәм әдәбияты буенча белемен тирәнәйтә, кызыксыну уята.

Түгәрәк татар теле һәм әдәбияты программасын кабатларга тиеш түгел.

Түгәрәкнең эш формасы күп төрле, монда укытучының иҗади сәләте зур роль уйный. Китап уку, аның турында фикер алышу, кечкенә докладлар төзү, язучы иҗатын өйрәнү, шигырь укучылар бәйгеләре оештыру, әдәби -музыкаль монтаж әзерләү, музейларга бару, җирле матбугат белән танышу, һ.б. бик күп төрле эш алымнары бар. Түгәрәкләрдә техник чаралар да куллану кирәк, эш барышында музыка яңгырату, магнитофон, телевизор, компьютер куллану эшне тагын да җанландыра.

Түгәрәк эше балаларның күзаллавын киңәйтергә, аңа яңалык алып килергә, рухи тәрбия бирергә дә тиеш. Халык авыз иҗатын, татар халык педагогикасын куллану, табигать белән аралашу түгәрәк эшләрен оештырганда укытучыга зур мөмкинлекләр ача.

**Тематик планлаштыру**

| № | Уку материалының темасы | Сәгать саны | Үткәрү вакыты | Фак. вакыты |
|---|---|---|---|---|
| 1-2 | 2025-2026 нчы уку елына түгәрәк эшенең планы белән таныштыру . Инструктаж үткәрү. Татар театр сәнгатенең роле, әһәмияте. | 2 | 01.09. 02.09. | |
| 3-4 | Аралашу кагыйдәләре. Театр сәнгатенең төп үзенчәлеге, аңа бәйле һөнәрләр (актер, режиссер, сценарист, рәссам, гример һ.б. ) белән якыннан танышу. | 2 | 08.09. 09.09. | |
| 5-6 | Татар сүз сәнгатенең күренекле вәкилләре. Татар театрының тарихы белән танышу.Театрга нигез салучылар турында кыскача белешмә. Беренче театр артистлары турында фикер алышу | 2 | 15.09. 16.09 | |
| 7-8 | Галиәсгар Камал исемендәге Татар Дәүләт академия театры турында белем туплау. Әлеге театрда эшләүче күренекле сәхнә осталары, режиссерлар һәм композиторлар турында мәгълүмат. | 2 | 22.09. 23.09. | |
| 9-10 | К. Тинчурин исемендәге Татар Дәүләт драма һәм комедия театры. Әлеге театрда эшләүче күренекле сәхнә осталары, режиссерлар һәм композиторлар турында белемнәрне баету. | 2 | 29.09. 30.09. | |
| 11-12 | Драма жанры төрләре турында мәгълүмат. (драма, комедия, трагедия) Классик драма әсәрләре, классик драматурглар иҗаты | 2 | 06.10 07.10 | |
| 13-14 | Драматурглар, (Туфан Миңнуллин, Зөлфәт Хәким һ.б.) аларның иҗатлары турында фикер алышу. | 2 | 13.10 14.10. | |
| 15-16 | Г.Кариев исемендәге яшь тамашачы театры эшчәнлеге. (артистлары, репертуары һәм тарихы.) “Сәйяр” труппасы эшчәнлеге. | 2 | 20.10 21.10. | |
| 17-18 | Якташ актерларыбыз, аларның иҗатлары турында фикер алышу. | 2 | 10.11. 11.11. | |
| 19-20 | Муса Җәлил исемендәге опера һәм балет театры турында мәгълүмат бирү. Материал туплау, чыгыш ясау. | 2 | 17.11 18.11. | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 21-22 | Муса Җәлил иҗатына багышланган “Гомерем минем моңлы бер җыр иде” әдәби-музыкаль кичә әзерләү. | 2 | 24.11<br>25.11 | |
| 23-24 | Әсәрне өйрәнү, үзләштерү этабы. Сәхнә серләренә өйрәнү. Видеоязмалар карау, бәя бирү, образлар иҗат итү. | 2 | 01.12<br>02.12 | |
| 25-26 | “Син театр турында нәрсәләр беләсең?” темасына викторина уздыру | 2 | 08.12<br>09.12 | |
| 27-28 | Әкиятләрдән өзекләрне сәхнәләштерү. (“Кем нәрсә ярата”, “Өч кыз”, ”Үги кыз”, һ.б.) | 2 | 15.12<br>16.12 | |
| 29-30 | Сөйләмдә уңышларым һәм җитешсезлекләрем. | 2 | 22.12<br>23.12 | |
| 31-32 | Проза әсәрләрен сәнгатьле уку күнегүләре. | 2 | 29.12<br>30.12 | |
| 33-34 | Җырлы-биюле уеннар өйрәнү. Шигъри әсәрләрне сәнгатьле уку. | 2 | 12.01<br>13.01 | |
| 35-36 | Сөйләм үзенчәлекләре. Сәнгатьле сөйләм үстерү. | 2 | 19.01<br>20.01 | |
| 37-38 | Киенү-бизәнү осталыгы. Декорациянең роле. | 2 | 26.01<br>27.01 | |
| 39-40 | Туфан Миңнуллинның иҗаты белән танышу. “Кәрлә-мәктәп баласы” спектакленең (әкият-тамаша) видеоязмасын карау. | 2 | 02.02<br>03.02 | |
| 41-42 | Туфан Миңнуллинның “Кәрлә-мәктәп баласы” спектаклен мәктәп укучылары сәхнәләштергән вариантын видеоязмадан карау. | 2 | 09.02<br>10.02 | |
| 43-44 | “Туган тел” бәйрәмендә катнашу. Районыбызның туган як музеена сәяхәт. | 2 | 16.02<br>17.02 | |
| 45-46 | “Кәрлә-мәктәп баласы” спектакленнән өзек өйрәнү. | 2 | 24.02<br>02.03 | |
| 47-48 | Туфан Миңнуллинның “Кәрлә-мәктәп баласы” спектакле. Әсәрнең идеясе, күтәрелгән проблемаларны ачыклау. | 2 | 03.03<br>09.03 | |
| 49-50 | Әсәрдәге тема, проблемаларны ачыклау. Рольләрне бүлешү һәм раслау. | 2 | 10.03<br>16.03 | |
| 51-52 | Сәхнәдә хәрәкәтләнү, үз-үзеңне тоту, мимика, жестлар.<br>Образларны өйрәнү. | 2 | 17.03<br>23.03 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 53-54 | Хисләрне җиткерү алымнары. Репетиция. Мимика, интонация, басым, сөйләм техникасы өстендә эш. | 2 | 24.03<br>06.04 | |
| 55-56 | “Туфан Миңнуллинның “Кәрлә-мәктәп баласы” ” спектакле өчен костюмнар әзерләү.<br>Сәхнә бизәлеше өчен декорация әзерләү | 2 | 07.04<br>13.04 | |
| 57-58 | Тавышны кую, гәүдә һәм кул хәрәкәтләрен өйрәнү.<br>Репетиция . Диалог, монолог. | 2 | 14.04<br>20.04 | |
| 59-60 | Образларга бәя бирү, характерларын өйрәнү “Кәрлә-мәктәп баласы” ” спектаклен сәхнәдә уйнауга әзерлек. | 2 | 21.04<br>27.04 | |
| 61-62 | Төркемдә һәм коллективта эшләү күнекмәләрен, сөйләм телен үстерү.<br>“Кәрлә-мәктәп баласы”” спектаклен мәктәп күләмендә сәхнәләштерү. | 2 | 28.04<br>04.05 | |
| 63-64 | Туфан Миңнуллин язган спектакльләренең, экият-тамашаларның актуальлеге. | 2 | 05.05<br>11.05 | |
| 65-66 | “Театр яктылыкка, нурга илтә” темасына конкурс уздыру.(КВН-викторина)<br>Казанга Г.Камал исемендәге (яңа) Татар Дәүләт академия театрына экскурсия оештыру | 2 | 12.05<br>18.05 | |
| 67-68 | Йомгаклау. Башкарылган эшләр буенча презентация, буклетлар ясау. Түгәрәк эшен йомгаклау, уңышлар һәм җитешсезлекләр турында сөйләшү. | 2 | 19.05<br>25.05 | |

**Программаның эчтәлеге**

Татар театрының чишмә башы. Театрга нигез салучылар турында кыскача белешмә. Театр артистлары турында фикер алышу.

Татарстандагы театрлар. Театр артистлары турында белешмә.

Г.Камал һәм К.Тинчурин - татар театрын оештыручылар. Аларның эшчәнлегенә күзәтү.Сөйләмдә уңышларым һәм җитешсезлекләрем.Сәхнәдә үз-үзеңне тоту кагыйдәләре белән танышу.

Галиәскар Камал исемендәге Татар дәүләт академия, Кәрим Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия, Курчак театры белән танышу. Туфан Миңнуллинның “Кәрлә-мәктәп баласы ”спектаклен сәхнәдә уйнау. Видеоязмасын карау. Рольләрне бүлешү. Сәхнә бизәлеше өчен декорацияләр, костюмнар әзерләү. Репетицияләр үткәрү, спектаклне 5-11нче сыйныф укучылары алдында күрсәтү.

“Син театр турында нәрсәләр беләсең?” темасына КВН-викторина уздыру. “Театр яктылыкка, нурга илтә” темасына конкурс уздыру.

**Уку елы ахырында укучылар белергә тиеш :**

Театр сәнгате, аның төп үзенчәлеге.
Татар театр сәнгате, аның тәүге адымнары, формалашу чоры, үткән юлы.
Милли театрыбыз, аның беренче карлыгачлары (Язучы-драматурглары, артист-актерлары, режиссерлары).
Драма жанрлары.
Классик драма әсәрләре, классик драматургларижаты.
Актерлыкбурычы, образгакерү һәмтоемлапсөйләү.
Режиссер күрсәтмәләрен аңлый, үти белү.
Мәдәниятне аңлый белүче, иҗади талантлы кеше булу.

**Укучылар өчен әдәбият:**

1. Мәктәп сәхнәсе. 1-2 кисәк.
2. Пионер сәхнәсе. 6-8 кисәк
3. Ш.Галиев.Күңеллесәхнә.-Казан, 1971.
4. Ш.Мостафин. Безнең сәхнә. –Казан, 1989.
5. Мәзәкләр җыентыгы.
6. Классик драматурглар иҗаты үрнәкләре.
7. И.Нуруллин. Драматургиядә жанр формалары.
8. Шәрифуллина Э.М. Җырлы бәйрәм. Мәктәпләрдә әдәби-музыкаль кичәләр үткәрү өчен кулланма. – Казан: Татарстан Республикасы “Хәтер” нәшрияты, 2011
9. Балалар фольклоры. Казан:/ Татарстан Республикасы “Хәтер” нәшрияты, 2009

**Укытучы өчен әдәбият.**

1. Хаков В.Х.Татар милли әдәби теле формалашу чорында драма әсәрләренең теле//Татар тел белеме мәсьәләләре. – Кит. 3 – Казан, 1969
2. Нуриев Г.-Р. С. Сәнгатьле уку. Методик ярдәмлек. – Казан: 2000
3. А.Әхмәдуллин. Сәхнә һәм тормыш. – Казан, 1976.
4. Р.Җиһаншина. Кунелем түреннән.
5. Төрле журналлар, альбомнар, белешмәләр, рәсем-фотолар, артист язмалары.
6. Әдәбиятдәреслекләре.
7. Сәхнә әсәрләре
8. Интернет ресурслар: mon.tatar.ru, edu.tatar.ru , infourok.ru, belem.ru.